# ЗАКОН
# РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

## О наделении органов местного самоуправления муниципальных районов и городских округов государственными полномочиями Республики Татарстан по оказанию в специализированных учреждениях услуг лицам, находящимся в общественных местах в состоянии алкогольного опьянения и утратившим способность самостоятельно передвигаться или ориентироваться в окружающей обстановке

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
22 июня 2017 года

### Статья 1. **Предмет регулирования настоящего Закона**

Настоящий Закон в соответствии с Федеральным законом от 6 октября 1999 года № 184-ФЗ «Об общих принципах организации законодательных (представительных) и исполнительных органов государственной власти субъектов Российской Федерации», Федеральным законом от 6 октября 2003 года № 131-ФЗ «Об общих принципах организации местного самоуправления в Российской Федерации», Законом Республики Татарстан от 28 июля 2004 года № 45-ЗРТ «О местном самоуправлении в Республике Татарстан», Законом Республики Татарстан от 22 декабря 2012 года № 87-ЗРТ «О регулировании отдельных вопросов в сфере охраны здоровья граждан в Республике Татарстан» регулирует отношения, связанные с наделением органов местного самоуправления муниципальных районов и городских округов в Республике Татарстан (далее – органы местного самоуправления) государственными полномочиями Республики Татарстан по оказанию в специализированных учреждениях услуг лицам, находящимся в общественных местах в состоянии алкогольного опьянения и утратившим способность самостоятельно передвигаться или ориентироваться в окружающей обстановке, не нуждающимся в оказании медицинской помощи.

Статья 2. **Государственные полномочия Республики Татарстан, которыми наделяются органы местного самоуправления**

Органы местного самоуправления наделяются государственными полномочиями Республики Татарстан по оказанию в специализированных учреждениях услуг лицам, находящимся в общественных местах в состоянии алкогольного опьянения и утратившим способность самостоятельно передвигаться или ориентироваться в окружающей обстановке, не нуждающимся в оказании медицинской помощи (далее – государственные полномочия).

Статья 3. **Наименования муниципальных образований в Республике Татарстан, органы местного самоуправления которых наделяются государственными полномочиями**

Государственными полномочиями наделяются органы местного самоуправления следующих муниципальных образований в Республике Татарстан: город Казань, «город Набережные Челны», Азнакаевский муниципальный район, Альметьевский муниципальный район, Бугульминский муниципальный район, Елабужский муниципальный район, Заинский муниципальный район, Зеленодольский муниципальный район, Лениногорский муниципальный район, Нижнекамский муниципальный район, Чистопольский муниципальный район.

Статья 4. **Срок, на который органам местного самоуправления передаются государственные полномочия**

Государственные полномочия передаются органам местного самоуправления на неограниченный срок.

Статья 5. **Финансовое обеспечение переданных органам местного самоуправления государственных полномочий**

1. Финансовое обеспечение переданных органам местного самоуправления государственных полномочий осуществляется за счет предоставляемых бюджетам муниципальных районов и городских округов субвенций из бюджета Республики Татарстан.

2. Расчет объема субвенций, предоставляемых бюджетам муниципальных районов и городских округов из бюджета Республики Татарстан для осуществления органами местного самоуправления государственных полномочий, производится в соответствии с Методикой расчета субвенций бюджетам муниципальных образований из бюджета Республики Татарстан для осуществления государственных полномочий Республики Татарстан по оказанию в специализированных учреждениях услуг лицам, находящимся в общественных местах в состоянии алкогольного опьянения и утратившим способность самостоятельно передвигаться или ориентироваться в окружающей обстановке, не

нуждающимся в оказании медицинской помощи, согласно приложению к настоящему Закону.

3. Объем субвенций, предоставляемых бюджетам муниципальных районов и городских округов из бюджета Республики Татарстан для осуществления органами местного самоуправления государственных полномочий, устанавливается законом Республики Татарстан о бюджете Республики Татарстан на очередной финансовый год.

Статья 6. **Материальные средства, передаваемые в безвозмездное пользование органам местного самоуправления для осуществления государственных полномочий**

1. Материальные средства, находящиеся в собственности Республики Татарстан, в случае необходимости обеспечения осуществления государственных полномочий, предусмотренных настоящим Законом, передаются в безвозмездное пользование органам местного самоуправления в соответствии с Перечнем передаваемых материальных средств.

Разработка Перечня передаваемых материальных средств, его утверждение и принятие решения о передаче материальных средств осуществляются органом исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченным в области имущественных отношений, на основании подготовленного с учетом предложений органов местного самоуправления обращения органа исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченного в сфере охраны здоровья граждан.

2. Органы местного самоуправления имеют право дополнительно использовать собственные материальные средства для осуществления переданных им государственных полномочий в случаях и порядке, предусмотренных уставом муниципального образования.

Статья 7. **Права и обязанности органов государственной власти Республики Татарстан при осуществлении органами местного самоуправления государственных полномочий**

1. Органы государственной власти Республики Татарстан при осуществлении органами местного самоуправления государственных полномочий имеют право:

1) принимать обязательные для исполнения нормативные правовые акты по вопросам осуществления переданных государственных полномочий и осуществлять контроль за их исполнением;

2) давать письменные предписания по устранению нарушений, допущенных органами местного самоуправления или их должностными лицами в ходе осуществления государственных полномочий, в том числе по устранению нарушений требований настоящего Закона;

3) осуществлять координацию деятельности органов местного самоуправления по вопросам осуществления государственных полномочий;

4) запрашивать документы, информацию и материалы, связанные с осуществлением государственных полномочий.

2. Органы государственной власти Республики Татарстан при осуществлении органами местного самоуправления государственных полномочий обязаны:

1) передать органам местного самоуправления в безвозмездное пользование материальные средства, необходимые для осуществления ими государственных полномочий;

2) рассматривать предложения органов местного самоуправления по вопросам осуществления государственных полномочий;

3) осуществлять контроль за реализацией органами местного самоуправления государственных полномочий, а также за использованием предоставленных на эти цели материальных и финансовых средств;

4) предоставлять органам местного самоуправления по их запросам информацию по вопросам осуществления государственных полномочий;

5) оказывать консультационную, организационную и методическую помощь органам местного самоуправления при осуществлении ими государственных полномочий.

Статья 8. **Права и обязанности органов местного самоуправления при осуществлении государственных полномочий**

1. Органы местного самоуправления при осуществлении государственных полномочий вправе:

1) издавать акты по вопросам реализации государственных полномочий;

2) дополнительно использовать собственные материальные и финансовые средства для осуществления переданных им государственных полномочий в случаях и порядке, предусмотренных уставом муниципального образования;

3) вносить в установленном порядке предложения в органы государственной власти Республики Татарстан по совершенствованию деятельности, связанной с осуществлением государственных полномочий;

4) получать в органах государственной власти Республики Татарстан консультационную и методическую помощь по вопросам осуществления государственных полномочий.

2. Органы местного самоуправления при осуществлении государственных полномочий обязаны:

1) определить органы местного самоуправления и должностных лиц органов местного самоуправления, ответственных за осуществление государственных полномочий;

2) вести учет и обеспечивать надлежащее использование материальных средств, переданных для осуществления государственных полномочий;

3) использовать финансовые средства, выделенные для осуществления государственных полномочий, по целевому назначению;

4) представлять в уполномоченные органы исполнительной власти Республики Татарстан отчеты об осуществлении государственных полномочий и расходовании финансовых средств;

5) оказывать необходимое содействие уполномоченным органам исполнительной власти Республики Татарстан в осуществлении контроля за реализацией органами местного самоуправления государственных полномочий;

6) возвратить неиспользованные финансовые средства, а также материальные средства в случае прекращения осуществления государственных полномочий.

Статья 9. **Порядок отчетности органов местного самоуправления об осуществлении государственных полномочий**

Отчеты об осуществлении государственных полномочий, переданных органам местного самоуправления, представляются органами местного самоуправления в уполномоченный орган исполнительной власти Республики Татарстан в сфере охраны здоровья граждан ежеквартально, в срок до 10 числа месяца, следующего за отчетным кварталом, по форме, установленной Кабинетом Министров Республики Татарстан.

Статья 10. **Контроль за осуществлением государственных полномочий органами местного самоуправления**

Контроль за осуществлением государственных полномочий, переданных органам местного самоуправления, осуществляется:

1) уполномоченным органом исполнительной власти Республики Татарстан в сфере охраны здоровья граждан путем:

запросов необходимых документов, отчетов и информации об исполнении государственных полномочий;

проведения выездных проверок деятельности органов местного самоуправления по осуществлению государственных полномочий согласно плану, ежегодно утверждаемому указанным органом, а также по мере необходимости внеплановых выездных проверок;

2) органом исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченным в области финансовой политики в части целевого использования финансовых средств, переданных для осуществления государственных полномочий, путем:

запросов необходимых документов, отчетов и информации об исполнении государственных полномочий;

проведения по мере необходимости выездных проверок деятельности органов местного самоуправления по осуществлению государственных полномочий, в том числе по результатам рассмотрения запрошенных ранее документов, отчетов, информации, а также в связи с выявленными фактами нарушения законодательства;

принятия необходимых мер по устранению нарушений и их предупреждению;

3) в случае передачи в безвозмездное пользование органам местного самоуправления материальных средств, находящихся в собственности Республики Татарстан, для обеспечения государственных полномочий, предусмотренных настоящим Законом, органом исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченным в области имущественных отношений, в части сохранности и

надлежащего использования государственного имущества, переданного органам местного самоуправления для осуществления государственных полномочий, путем:

запросов необходимых документов, отчетов и информации об исполнении государственных полномочий;

проведения по мере необходимости выездных проверок деятельности органов местного самоуправления по осуществлению государственных полномочий, в том числе по результатам рассмотрения запрошенных ранее документов, отчетов, информации, а также в связи с выявленными фактами нарушения законодательства;

принятия необходимых мер по устранению нарушений и их предупреждению;

4) органом исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченным в области юстиции, в части обеспечения соответствия муниципальных правовых актов, принятых органами местного самоуправления по вопросам переданных им государственных полномочий, законодательству Российской Федерации и Республики Татарстан путем:

запросов необходимой информации, проектов муниципальных правовых актов, муниципальных правовых актов, принятых органами местного самоуправления во исполнение переданных государственных полномочий;

проведения правовой экспертизы и анализа проектов муниципальных правовых актов и муниципальных правовых актов, принятых органами местного самоуправления во исполнение переданных государственных полномочий.

Статья 11. **Условия и порядок прекращения осуществления органами местного самоуправления государственных полномочий**

1. Прекращение осуществления органами местного самоуправления государственных полномочий производится законом Республики Татарстан в случаях:

1) неисполнения или ненадлежащего исполнения органами местного самоуправления требований законодательства;

2) неисполнения органами местного самоуправления и их должностными лицами предписаний об устранении нарушений настоящего Закона;

3) изменения федерального законодательства или законодательства Республики Татарстан, в результате которого исполнение органами местного самоуправления государственных полномочий становится невозможным;

4) в иных случаях, предусмотренных законодательством.

2. Прекращение осуществления органами местного самоуправления государственных полномочий влечет за собой возврат неиспользованных финансовых средств, а также материальных средств, переданных для осуществления государственных полномочий.

3. В случае неисполнения или ненадлежащего исполнения органами местного самоуправления требований законодательства по осуществлению государственных полномочий уполномоченный орган исполнительной власти Республики Татарстан в сфере охраны здоровья граждан в течение 10 дней со дня выявления указанных нарушений направляет в органы местного самоуправления предписание об их устранении.

4. Предписание об устранении выявленных нарушений подлежит обязательному рассмотрению не позднее чем в десятидневный срок со дня его поступления в орган местного самоуправления. О результатах рассмотрения предписания незамедлительно сообщается в письменной форме в уполномоченный орган исполнительной власти Республики Татарстан в сфере охраны здоровья граждан.

5. В случаях, предусмотренных частью 1 настоящей статьи, уполномоченный орган исполнительной власти Республики Татарстан в сфере охраны здоровья граждан вносит на рассмотрение в Кабинет Министров Республики Татарстан предложение о прекращении осуществления органами местного самоуправления государственных полномочий и соответствующий проект закона Республики Татарстан.

Статья 12. **Заключительные положения**

1. Настоящий Закон вступает в силу с 1 января 2018 года.

2. Нормативные правовые акты органов государственной власти Республики Татарстан и органов местного самоуправления муниципальных образований в Республике Татарстан подлежат приведению в соответствие с настоящим Законом в течение трех месяцев со дня вступления его в силу.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

ОБЩИЙ ОТДЕЛ / ГОМУМИ БҮЛЕК (Аппарат Президента Республики Татарстан)

Казань, Кремль
10 июля 2017 года
№ 50-ЗРТ

Приложение
к Закону Республики Татарстан «О наделении органов местного самоуправления муниципальных районов и городских округов государственными полномочиями Республики Татарстан по оказанию в специализированных учреждениях услуг лицам, находящимся в общественных местах в состоянии алкогольного опьянения и утратившим способность самостоятельно передвигаться или ориентироваться в окружающей обстановке»

# МЕТОДИКА
# РАСЧЕТА СУБВЕНЦИЙ БЮДЖЕТАМ МУНИЦИПАЛЬНЫХ ОБРАЗОВАНИЙ ИЗ БЮДЖЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ДЛЯ ОСУЩЕСТВЛЕНИЯ ГОСУДАРСТВЕННЫХ ПОЛНОМОЧИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ОКАЗАНИЮ В СПЕЦИАЛИЗИРОВАННЫХ УЧРЕЖДЕНИЯХ УСЛУГ ЛИЦАМ, НАХОДЯЩИМСЯ В ОБЩЕСТВЕННЫХ МЕСТАХ В СОСТОЯНИИ АЛКОГОЛЬНОГО ОПЬЯНЕНИЯ И УТРАТИВШИМ СПОСОБНОСТЬ САМОСТОЯТЕЛЬНО ПЕРЕДВИГАТЬСЯ ИЛИ ОРИЕНТИРОВАТЬСЯ В ОКРУЖАЮЩЕЙ ОБСТАНОВКЕ

1. Настоящая Методика предназначена для расчета объема субвенций, предоставляемых бюджетам муниципальных районов и городских округов из бюджета Республики Татарстан для осуществления органами местного самоуправления государственных полномочий Республики Татарстан по оказанию в специализированных учреждениях услуг лицам, находящимся в общественных местах в состоянии алкогольного опьянения и утратившим способность самостоятельно передвигаться или ориентироваться в окружающей обстановке, не нуждающимся в оказании медицинской помощи (далее – государственные полномочия).

2. Общий объем субвенций определяется по формуле:

$$V_{sb\ svod} = \sum_{i=1}^{n} V_{sd\ rn} ,$$

где:

$V_{sb\ svod}$ – общий объем субвенций бюджетам муниципальных образований для осуществления государственных полномочий;

$V_{sd\ rn}$ – объем субвенций муниципальному образованию для осуществления государственных полномочий;

$n$ – число муниципальных образований, наделенных государственными полномочиями.

3. Объем субвенций, предоставляемых $i$-му муниципальному образованию из бюджета Республики Татарстан для осуществления органами местного самоуправления государственных полномочий, рассчитывается по формуле:

$$V^{i}_{sd\,rn} = Ns_{f} \times K^{i} \times q^{i} \times p\ ,$$

где:

$Ns_{f}$ - норматив стоимости оказания услуги, рублей на койко-день;

$K^{i}$ - корректирующий (поправочный) коэффициент $i$-го муниципального образования, учитывающий различия в инфраструктурной обеспеченности и иные факторы, влияющие на значение норматива стоимости оказания услуги, устанавливаемый Кабинетом Министров Республики Татарстан;

$q^{i}$ – количество коек в специализированной организации $i$-го муниципального образования;

$p$ – число дней в году.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына җәмәгать урыннарында исерек хәлдә булган һәм мөстәкыйль рәвештә йөрү яисә тирә-юньдә ориентлашу сәләтен югалткан затларга махсуслаштырылган учреждениеләрдә хезмәт күрсәтү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 22 июнендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге законны җайга салу предметы**

Әлеге Закон «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә Татарстан Республикасында муниципаль районнар һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына (алга таба – җирле үзидарә органнары) җәмәгать урыннарында исерек хәлдә булган һәм мөстәкыйль рәвештә йөрү яисә тирә-юньдә ориентлашу сәләтен югалткан, медицина ярдәменә мохтаҗ булмаган затларга махсуслаштырылган учреждениеләрдә хезмәт күрсәтү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирүгә бәйле мөнәсәбәтләрне җайга сала.

2 статья. **Җирле үзидарә органнарына бирелә торган Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләре**

Җирле үзидарә органнарына җәмәгать урыннарында исерек хәлдә булган һәм мөстәкыйль рәвештә йөрү яисә тирә-юньдә ориентлашу сәләтен югалткан, медицина ярдәменә мохтаҗ булмаган затларга махсуслаштырылган

учреждениеләрдә хезмәт күрсәтү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләре (алга таба – дәүләт вәкаләтләре) бирелә.

**3 статья. Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләре бирелә торган муниципаль берәмлекләрнең исемнәре**

Дәүләт вәкаләтләре Татарстан Республикасында түбәндәге муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына бирелә: Казан шәһәре, «Чаллы шәһәре», Азнакай муниципаль районы, Әлмәт муниципаль районы, Бөгелмә муниципаль районы, Алабуга муниципаль районы, Зәй муниципаль районы, Зеленодольск муниципаль районы, Лениногорск муниципаль районы, Түбән Кама муниципаль районы, Чистай муниципаль районы.

**4 статья. Җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләре тапшырыла торган вакыт**

Дәүләт вәкаләтләре җирле үзидарә органнарына чикләнмәгән вакытка тапшырыла.

**5 статья. Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен финанс ягыннан тәэмин итү**

1. Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен финанс ягыннан тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гамәлгә ашырыла.

2. Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына бирелә торган субвенцияләр күләмен исәпләп чыгару Җәмәгать урыннарында исерек хәлдә булган һәм мөстәкыйль рәвештә йөрү яисә тирә-юньдә ориентлашу сәләтен югалткан, медицина ярдәменә мохтаҗ булмаган затларга махсуслаштырылган учреждениеләрдә хезмәт күрсәтү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына субвенцияләрне исәпләп чыгару методикасы нигезендә әлеге Законга кушымта буенча башкарыла.

3. Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына бирелә торган субвенцияләр күләме чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.

6 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарына түләүсез файдалануга тапшырыла торган матди чаралар**

1. Татарстан Республикасы милкендәге матди чаралар, әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү кирәк булганда, Тапшырыла торган матди чаралар исемлеге нигезендә җирле үзидарә органнарына түләүсез файдалануга тапшырыла.

Тапшырыла торган матди чаралар исемлеген әзерләү, раслау һәм матди чараларны тапшыру турында карар кабул итү Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге вәкаләтле органының җирле үзидарә органнары тәкъдимнәрен исәпкә алып әзерләнгән мөрәҗәгате нигезендә башкарыла.

2. Җирле үзидарә органнары үзләренә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль берәмлек уставында каралган очракларда һәм тәртиптә өстәмә рәвештә үз матди чараларыннан файдаланырга хокуклы.

7 статья. **Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының хокуклары һәм бурычлары**

1. Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары түбәндәгеләргә хокуклы:

1) тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча үтәлүе мәҗбүри булган норматив хокукый актлар кабул итәргә һәм аларның үтәлешен тикшереп торырга;

2) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру барышында җирле үзидарә органнары яисә аларның вазыйфаи затлары тарафыннан җибәрелгән хокук бозуларны бетерү, шул исәптән әлеге Закон таләпләрен бозуларны бетерү буенча язма күрсәтмәләр бирергә;

3) җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча эшчәнлеген координацияләүне гамәлгә ашырырга;

4) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле документлар, мәгълүмат һәм материаллар соратып алырга.

2. Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

1) җирле үзидарә органнарына алар тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле матди чараларны түләүсез файдалануга тапшырырга;

2) җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча тәкъдимнәрен карарга;

3) җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруын, шулай ук шушы максатлар өчен бирелгән матди һәм финанс чараларыннан файдалануын тикшереп торырга;

4) җирле үзидарә органнарына аларның соратулары буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча мәгълүмат бирергә;

5) җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда аларга консультатив, оештыру һәм методик ярдәм күрсәтергә.

8 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда җирле үзидарә органнарының хокуклары һәм бурычлары**

1. Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда түбәндәгеләргә хокуклы:

1) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча актлар чыгарырга;

2) муниципаль берәмлек уставында каралган очракларда һәм тәртиптә үзләренә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен өстәмә рәвештә үз матди һәм финанс чараларыннан файдаланырга;

3) билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле эшчәнлекне камилләштерү буенча тәкъдимнәр кертергә;

4) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарында дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча консультатив һәм методик ярдәм алырга.

2. Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

1) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җаваплы җирле үзидарә органнарын һәм җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларын билгеләргә;

2) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тапшырылган матди чараларның исәбен алып барырга һәм алардан тиешлечә файдалануны тәэмин итәргә;

3) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бирелгән финанс чараларыннан максатчан файдаланырга;

4) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнарына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру һәм финанс чараларын тоту турында хисаплар тапшырырга;

5) җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруларын тикшереп торуны башкаруда Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнарына кирәкле ярдәм күрсәтергә;

6) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру туктатылган очракта файдаланылмаган финанс чараларын, шулай ук матди чараларны кире кайтарырга.

9 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында җирле үзидарә органнарының хисап бирү тәртибе**

Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында хисаплар җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге вәкаләтле органына Татарстан Республикасы Министрлар

Кабинеты билгеләгән рәвештә квартал саен хисап кварталыннан соң килә торган айның 10 числосына кадәр тапшырыла.

### 10 статья. Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тикшереп тору

Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тикшереп тору түбәндәгеләр тарафыннан башкарыла:

1) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча эшчәнлегенә күрсәтелгән орган тарафыннан ел саен раслана торган план нигезендә күчмә тикшерүләр, шулай ук, кирәк булганда, планнан тыш күчмә тикшерүләр үткәрү;

2) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең финанс сәясәте өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тапшырылган финанс чараларыннан максатчан файдалану өлешендә түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча эшчәнлегенә, шул исәптән элек соратып алынган документларны, хисапларны, мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча, шулай ук закон бозуның ачыкланган фактларына бәйле рәвештә дә, кирәк булганда, күчмә тикшерүләр үткәрү;

хокук бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча кирәкле чаралар күрү;

3) җирле үзидарә органнарына әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы милкендәге матди чараларны түләүсез файдалануга тапшырган очракта, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тапшырылган дәүләт мөлкәтен саклау һәм аннан тиешенчә файдалану өлешендә түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча эшчәнлегенә, шул исәптән элек соратып алынган документларны, хисапларны, мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча, шулай ук закон бозуның ачыкланган фактларына бәйле рәвештә дә, кирәк булганда, күчмә тикшерүләр үткәрү;

хокук бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча кирәкле чаралар күрү;

4) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең юстиция өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан җирле үзидарә органнары үзләренә тапшырылган дәүләт вәкаләтләре мәсьәләләре буенча кабул иткән муниципаль хокукый актларның

Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына туры килүен тәэмин итү өлешендә түбәндәге юллар белән:

кирәкле мәгълүматны, тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен башкару өчен җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән муниципаль хокукый актлар проектларын, муниципаль хокукый актларны соратып алу;

тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен башкару өчен җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән муниципаль хокукый актлар проектларына, муниципаль хокукый актларга хокукый экспертиза уздыру һәм анализ ясау.

11 статья. **Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны туктату шартлары һәм тәртибе**

1. Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы законы белән түбәндәге очракларда туктатыла:

1) җирле үзидарә органнары законнар таләпләрен үтәмәгәндә яисә тиешенчә үтәмәгәндә;

2) җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары әлеге Законны бозуларны бетерү турындагы күрсәтмәләрне үтәмәгәндә;

3) федераль законнар яисә Татарстан Республикасы законнары җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен башкару мөмкинлеген юкка чыгарырлык итеп үзгәртелгәндә;

4) законнарда каралган башка очракларда.

2. Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны туктату дәүләт вәкаләтләрен башкару өчен тапшырылган файдаланылмаган финанс чараларын, шулай ук матди чараларны кире кайтаруга китерә.

3. Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча законнар таләпләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге вәкаләтле органы күрсәтелгән хокук бозулар ачыкланган көннән алып 10 көн эчендә җирле үзидарә органнарына аларны бетерү турында күрсәтмә җибәрә.

4. Ачыкланган хокук бозуларны бетерү турындагы күрсәтмә җирле үзидарә органына кергән көненнән алып 10 көннән дә соңга калмыйча мәҗбүри рәвештә каралырга тиеш. Күрсәтмәне карау нәтиҗәләре хакында Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге вәкаләтле органына кичекмәстән язма рәвештә хәбәр ителә.

5. Әлеге статьяның 1 өлешендә каралган очракларда Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге вәкаләтле органы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каравына җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны туктату турында тәкъдим һәм тиешле Татарстан Республикасы законы проекты кертә.

12 статья. **Йомгаклау нигезләмәләре**

1. Әлеге Закон 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары әлеге Закон үз көченә кергән көннән алып өч ай эчендә аңа туры китерелергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2017 ел, 10 июль
№ 50-ТРЗ

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына җәмәгать урыннарында исерек хәлдә булган һәм мөстәкыйль рәвештә йөрү яисә тирә-юньдә ориентлашу сәләтен югалткан затларга махсуслаштырылган учреждениеләрдә хезмәт күрсәтү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына кушымта

# ҖӘМӘГАТЬ УРЫННАРЫНДА ИСЕРЕК ХӘЛДӘ БУЛГАН ҺӘМ МӨСТӘКЫЙЛЬ РӘВЕШТӘ ЙӨРҮ ЯИСӘ ТИРӘ-ЮНЬДӘ ОРИЕНТЛАШУ СӘЛӘТЕН ЮГАЛТКАН ЗАТЛАРГА МАХСУСЛАШТЫРЫЛГАН УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРДӘ ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮ БУЕНЧА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ВӘКАЛӘТЛӘРЕН ГАМӘЛГӘ АШЫРУГА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БЮДЖЕТЫННАН МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘР БЮДЖЕТЛАРЫНА СУБВЕНЦИЯЛӘРНЕ ИСӘПЛӘП ЧЫГАРУ МЕТОДИКАСЫ

1. Әлеге Методика җирле үзидарә органнары тарафыннан җәмәгать урыннарында исерек хәлдә булган һәм мөстәкыйль рәвештә йөрү яисә тирә-юньдә ориентлашу сәләтен югалткан, медицина ярдәменә мохтаҗ булмаган затларга махсуслаштырылган учреждениеләрдә хезмәт күрсәтү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен (алга таба – дәүләт вәкаләтләре) гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына бирелә торган субвенцияләр күләмен исәпләп чыгару өчен билгеләнә.

2. Субвенцияләрнең гомуми күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$V_{sb\ svod} = \sum_{i=1}^{n} V_{sd\ rn} ,$$

монда:

$V_{sb\ svod}$ – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль берәмлекләр бюджетларына субвенцияләрнең гомуми күләме;

$V_{sd\ rn}$ – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль берәмлеккә субвенцияләр күләме;

$n$ – дәүләт вәкаләтләре бирелгән муниципаль берәмлекләр саны.

3. Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан $i$ муниципаль берәмлегенә бирелә торган субвенцияләр күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$V^{i}_{sd\ rn} = Ns_{f} \times K^{i} \times q^{i} \times p ,$$

монда:

$Ns_{f}$ – хезмәт күрсәтү бәясе нормативы, бер койка-көнгә сум;

$K^{i}$ – $i$ муниципаль берәмлегенең инфраструктура белән тәэмин ителештәге аермаларны һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган хезмәт күрсәтү бәясе нормативы күрсәткеченә йогынты ясаучы башка факторларны исәпкә ала торган корректировка кертүче (төзәтү) коэффициенты;

$q^{i}$ – $i$ муниципаль берәмлегенең махсуслаштырылган оешмасындагы койкалар саны;

$p$ – елдагы көннәр саны.